**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Үчәлле авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Үчәлле авылы №60 02 август 2017 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Советының 2016 елның 19 апрелендәге 31 номерлы “Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында»гы карарын үз көчен югалткан дип тану турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру тәртибе турында» 2017 елның 19 июлендәге 56 номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә

Үчәлле авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Советының 2016 елның 19 апрелендәге 31 номерлы “Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында»гы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә

Рәис Г.М.Төхвәтуллина